ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 126 от «19» 03 2020 г.

Шәһәр һәм район территорияләрен чистарту
буенча санитар- экологик икеайлык
игълан итү турында

Санитар-эпидемиологик һәм экологик хәлне яхшырту, кеше саулыгына әйләнә-тирә мохитнең зарарлы һәм куркыныч факторлары йогынтысы дәрәҗәсен киметү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 24 февралендә кабул ителгән б-388 нче санлы боерыгын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. 2020 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр шәһәр һәм район торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитария-экология икеайлыгын игълан итәргә. (алга таба- икеайлык).

2. Икеайлыкны үткәрү эшләрен координацияләү өчен район штабын төзергә һәм аның составын расларга (килешү буенча) (1 нче кушымта).

3. Мамадыш муниципаль районы авыл җирлекләре һәм Мамадыш шәһәре башкарма комитетлары җитәкчеләренә, оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, оешмалар, предприятиеләр һәм учреждениеләр җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- ведомство карамагындагы территорияләрнең санитар-экологик хәлен яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар планын эшләргә һәм 2020 елның 29 мартына кадәр расларга;

-икеайлык үткәрү эшләрен координацияләү өчен оператив штаблар төзергә.

4. Шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

- авыл җирлекләре һәм Мамадыш шәһәре территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләре, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләре үтәлешен тикшерүдә тотуны көчәйтү өлешендә җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары эшен активлаштыруны;

-су объектларының су саклау зоналарын, пляжларны, скверларны, паркларны, балалар мәйданчыкларын, азык-төлек һәм әйбер базарларын, халык күпләп ял итә торган урыннарны, ял базаларын, зиратларны, шәхси торак сектор территорияләрен, ташландык биналар, тузган төзелешләрне һәм корылмаларны

санитар чистарту, аларны дератизацион эшкәртү, автомобиль юлларының юл буе полосалары, контейнер мәйданчыкларын төзү һәм ремонтлау буенча чаралар үткәрергә;

- каты көнкүреш һәм биологик калдыклар (үләт базлары) полигоннарын тиешенчә карап тотуны һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү һәм алар янындагы урыннарны санитар чистарту буенча чаралар күрүне;

- терлекчелек комплекслары калдыкларын рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү буенча чаралар күрүне;

- «Татарстан Республикасы Экологик картасы» геомәгълүмат системасы http://ecokarta.tatar.ru/ ярдәмендә ведомство буйсынуындагы территориядә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү мониторингын гамәлгә ашыруны, шул исәптән «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы, «Мәктәп экопатруле» мобиль кушымтасы чаралары буенча кергән хәбәрләрне дә исәпкә алып;

5. Мамадыш муниципаль районының административ комиссиясе секретарена һәм Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә шәһәр һәм район территорияләрен язгы санитар чистарту һәм төзекләндерү эшләрен координацияләүне тәкъдим итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 24 февралендә кабул ителгән б-388 нче санлы боерыгына теркәлеп килүче кушымталар нигезендә:1 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча икеайлык үткәрү эшләре барышы турындагы мәгълүматны атна саен, чәршәмбе, 2 нче санлы форма буенча 2020 елның 8, 22 апрелендә, 6, 20 һәм 27 маенда Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына җибәрүне.

6.ҖЧЖ “Эколидер”оешмасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

-Каты көнкүреш калдыкларын кабул итү, сортларга аеру һәм күмү буенча эш алып барырга, чүп чыгару өчен махсус машина паркы һәм чүп полигоннарының нәтиҗәле эшен тәэмин итәргә;

7. Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (С.Н.Ханова) икеайлык кысаларында үткәрелә торган эшне “Нократ” (“Вятка”) газетасында әледән-әле яктыртып торуны тәэмин итәргә.

8.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының 19 03 2020 ел,
№ 126 карарына
1 нче кушымта
2020 елның "19" 03 2020

# Мамадыш муниципаль районында санитар-экологик хәлне яхшырту буенча икеайлык үткәрү буенча район штабы
# СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Дәрҗеманов Илшат Миннеәсгать улы | - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, штаб рәисе; |
| Хуҗаҗанов Муса Рөстәм улы | - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, штаб рәисе урынбасары; |
| Никитин Вадим Ильич | - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары, штаб рәисе урынбасары; |
| Гарипов Рашит Мухаметдинович | - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе, штаб рәисе урынбасары; |

**Штаб әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Дәүләтшин Айрат Бәхтияр улы | - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеше бүлеге башлыгы; |
| Хаҗиев Ренат Рифат улы | - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы; |
| Кәмәлетдинова Олеся Сергеевна | - - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының административ комиссиясе секретаре; |
| Низамов Наил Кыям улы | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча); |
| Кашапов Илнур Гыймран улы | - «Мамадыш муниципаль районы һәм Мамадыш шәһәре идарәче компаниясе» ҖЧҖ директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча); |
| Гатиятуллин Рәис Сабирҗан улы | - «Мамадыш торак-коммуналь хезмәтләр» ҖЧҖ директоры (килешү буенча); |
| Котдусов Руслан Раиф улы | - «Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ башлыгы (килешү буенча); |
| Руднев Павел Сергеевич | - Мамадыш районы буенча янгын сүндерү-коткару бүлеге башлыгы (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| Хәсәнов Әхәт Әгъмал улы | - “Мамадыш урманчылыгы” ДКУ җитәкче-урманчысы (килешү буенча); |
| Шамилов Альберт Фәрхетдин улы | - “Кама урманчылыгы” ДКУ җитәкче-урманчысы (килешү буенча); |
| Барсуков Александр Юрьевич | «Татавтодор» ААҖ Мамадыш филиалы директоры (килешү буенча); |
| Шәрәфиев Рафил Габделхай улы | - Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Кама буе территориаль идарәсе баш белгече (килешү буенча); |
| Мәснәвиева Мәдинә Хәмитовна | - Россия кулланучылар күзәтчелегенең Саба, Мамадыш һәм Кукмара районнарында Татарстан Республикасы буенча территориаль идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| Ханова Светлана Наил кызы | - «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Мамадыш-информ» җитәкчесе (килешү буенча); |

Мамадыш муниципаль районының авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча)